

22 июньдә Россиядә Хәтер һәм кайгы коне - Боек Ватан сугышы башланган кон билгеләп vтелде. Ә Боек Жинvнен 80-еллыгы һәм музейнын 15 еллык юбилее елында Рузаевка шәһәренен 10нчы мәктәбендә патриотик тәрбия vзәген оештыручы Фәризә Рәхим кызы Киселева, 9 А сыйныф экскурсоводлары Никита Кулагин, Алина Мухаева, Алина Атикова белән 1-9 нчы сыйныфларда «10нчы мәктәп укытучылары-фронтовиклары» дигән Жинv дәресләре vткәрде.

Дәресләрнен кереш сvзе булып укытучыларнын, Рузаевка шәһәре мәктәпләре музейларын оештыручыларнын,  китапханәчеләрнен, мәктәпне тәмамлаучыларнын жылы котлаулары булды.
Музейны булдыру титаник хезмәтне кем белә - башында торган оештыручы белә. Талантлы һәм максатчан Фәризә Рәхим кызы идеясе белән мәктәптә музей тозелә. «Боек Ватан сугышы» темасын ойрәнгәндә туган якны ойрәнv материалын куллану дигән диплом эшен ул университетнын тарих факультетында гына тvгел, тормышта да, мәктәптә дә «бишле» билгесенә яклады. «Үз баласын» бvген дә саклый: музей кинәшмәсенә булыша, патриотик форумнар, Батырлык дәресләре vткәрә... Кvптән тvгел «Музей - патриотизм чишмәсе» эчтәлекле экспозициясендә музейнын барлыкка килv тарихы, Боек Ватан сугышы ветераннары, мәктәпне тәмамлаучылар - СВОда катнашучылар тупланган: Батырлык дәресләре очен бай материал.
- Музей булдыру очен vз эшенне яратырга, аны vстерергә, киләчәккә этәрергә кирәк, - ди 10 нчы мәктәпнен укытучы-филологы Галия Наиль кызы Невлютова. - Мәктәп укучылары фронтовик-укытучылар Косырев Михаил Михайлович белән Шитов Иван Павловичнын биографияләре һәм хәрби батырлыклары турында белделәр. Ә бит мәктәп укучыларын патриотлылыгы укыту һәм тәрбияләv процессында формалаша. Беренче сыйныф укучылары тугызынчы сыйныф укучылары белән беррәттән «Хәтер» проектында да катнашалар. Безнен бурычыбыз - батыр якташларыбыз турында истәлек саклау. Патриотик тәрбия мәктәп эшенен нәтижәлелеге укытучыларнын һәм укучыларнын әзерлек дәрәжәсе һәм омтылышы белән vлчәнә, vзенен гражданлык һәм патриотик бурычын vтәv, туган ягыбызнын һәм кече Ватаныбызнын чәчәк атуына керткән реаль олешләре белән. Мона мисал Фәризә Рәхим кызы Киселева.


80
ПОБЕДА!
ПОЛК
ДИПЛОМ